**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Иске Кармәт авыл җирлеге башлыгы**

**Карар**

**05.11.2024 ел** **№ 1**

**“Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегенең Иске Кармәт авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы «Иске Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясына ярашлы

Карар итәм:

1. 2024 елның 15 ноябрендә ТР, Аксубай муниципаль районы, Иске Кармәт авылы, Ленин ур., 37 йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегенең Иске Кармәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 14 сәгать 00 минутка билгеләнсен.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

1) Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегенең Иске Кармәт авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, беренче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, СВОда катнашучы мобилизацияләнгән, контрактчылардан һәм аларның гаилә әгъзаларынан тыш, 2025 елда 1250 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

**I. торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу, кышкы юлларны тоту, кышкы чорда юлларны кардан чистарту өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу);

**II. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- урамнарны яктырту (урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (елга төбен чистарту һәм тирәнәйтү, торбалар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (генератор сатып алу).

**III. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (насос сатып алу).

**IV. Ритуаль хезмәт оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:**

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратны киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу).

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Иске Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт авыл җирлеге башлыгы: А.В.Парфенов